| | |
|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

# О единовременной денежной выплате некоторым категориям граждан Российской Федерации в связи с 80-й годовщиной Победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 годов

В связи с 80-й годовщиной Победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 годов **постановляю**:

1. Произвести в апреле – мае 2025 года единовременную денежную выплату следующим категориям граждан Российской Федерации, постоянно проживающих на территории Республики Татарстан:

инвалидам Великой Отечественной войны, ветеранам Великой Отечественной войны из числа лиц, указанных в подпунктах 1–3 пункта 1 статьи 2 Федерального закона от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах», бывшим несовершеннолетним узникам концлагерей, гетто и других мест принудительного содержания, созданных фашистами и их союзниками в период Второй мировой войны, – в размере 50 000 рублей;

вдовам (вдовцам) военнослужащих, погибших в период войны с Финляндией, Великой Отечественной войны, войны с Японией, вдовам (вдовцам) умерших инвалидов Великой Отечественной войны и участников Великой Отечественной войны, ветеранам Великой Отечественной войны из числа лиц, указанных в подпункте 4 пункта 1 статьи 2 Федерального закона от 12 января 1995 года № 5-ФЗ «О ветеранах», – в размере 10 000 рублей.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с исполнением настоящего Указа, в том числе расходов на доставку единовременной денежной выплаты.

3. Министерству труда, занятости и социальной защиты Республики Татарстан обеспечить предоставление единовременной денежной выплаты гражданам Российской Федерации, указанным в пункте 1 настоящего Указа, по месту получения ими мер социальной поддержки.

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

**Раис Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
28 февраля 2025 года
№ 168

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе гражданнарының кайбер категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында**

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. 2025 елның апрель – май айларында Татарстан Республикасы территориясендә даими яши торган Россия Федерациясе гражданнарының түбәндәге категорияләренә бер тапкыр акчалата түләү бирергә:

«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 1 пунктындагы 1–3 пунктчаларында күрсәтелгән затлардан булган Бөек Ватан сугышы инвалидларына, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан корылган концлагерьлар, гетто һәм башка төрле ирексезләп ябып тоту урыннарында булган элеккеге балигъ булмаган тоткыннарга – 50 000 сум күләмендә;

Финляндия белән сугыш, Бөек Ватан сугышы, Япония белән сугыш чорында һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең тол хатыннарына (тол ирләренә), вафат булган Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә), «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 1 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән затлардан булган Бөек Ватан сугышы ветераннарына – 10 000 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны, шул исәптән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне китертүгә тотыла торган чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алар социаль ярдәм чаралары ала торган урыннарда бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 28 февраль
№ 168